СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ФЕДОТОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ФЕДОТОВКА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

2023 елның 3 июле №24

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 17 ноябрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә яңа редакциядә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 17 ноябрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

**«4. Башкарма комитет вәкаләтләре**

Куелган бурычларны гамәлгә ашыру һәм үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен Башкарма комитет түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга мөмкин.

1.Җирлекнең Башкарма комитеты:

1) планлаштыру, бюджет, финанс һәм исәпкә алу өлкәсендә:

җирлек бюджеты проектын, җирлекне комплексы социаль-икътисадый үстерү планнары һәм программалары проектларын эшли;

-җирлек бюджетын үтәүне тәэмин итә, җирлекне комплексы социаль-икътисадый үстерү планнарын һәм программаларын үтәүне оештыра;

-җирлек бюджетының үтәлеше турында хисап, җирлекнең комплексы социаль-икътисадый үсеше планнарының һәм программаларының үтәлеше турында хисаплар әзерли;

- җирлекнең икътисады һәм социаль өлкәсе торышын чагылдыра торган статистик күрсәткечләрне җыюны һәм күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнарына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тапшыруны оештыра;

2) җирлек территориясендә муниципаль милеккә идарә итү, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

- җирлекнең муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итә, муниципаль милек объектларын төзү, сатып алу, алардан файдалану, кушу һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итә;

- җирлек Советы карары белән билгеләнә торган очракларда җирлек Советының муниципаль милекне читләштерү, муниципаль милекне исәптән төшерү, шул исәптән хосусыйлаштыру турындагы тәкъдимнәрен әзерли һәм килештерүгә кертә;

- муниципаль милектәге предприятиеләр, оешмалар белән җирлекнең икътисадый һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек турында шартнамәләр төзи;

җирлек территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләр төзүгә ярдәм итә;

-җирлек советы билгеләгән тәртип нигезендә муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзи, аларның эшчәнлек максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, муниципаль казна учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итә һәм муниципаль биремне бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан үтәүне финанс белән тәэмин итә, шулай ук муниципаль учреждениеләрне һәм предприятиеләрне үзгәртеп оештыру һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итә, контракт нигезендә билгели һәм аларның җитәкчеләрен биләгән вазыйфасыннан азат итә;

-җирлекне төзекләндерү, халыкка коммуналь хезмәт күрсәтү, социаль инфраструктура объектларын төзү һәм ремонтлау, продукция җитештерү, халыкның көнкүреш һәм социаль - мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле хезмәтләр күрсәтү, җирлекнең үз матди һәм финанс чараларын кулланып башка эшләр башкаруга заказ бирүче булып тора;

-авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә ярдәм итә, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыра;

3) халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

-халыкны элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- ялны оештыру һәм халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

- җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

-җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра;

-җирлектә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр кыла;

- каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

- җирлек чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

4) төзекләндерү өлкәсендә:

- адреслар бирү, адреслар үзгәртү, аннулирование, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге җирле юлларыннан тыш), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, аннулировать итү, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыру;

-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

- җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына иректе керүен тәэмин итү дә керә.

- Үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә карар кабул итү, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында, яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына туры китерү турында карар кабул итү.

5) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә:

-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру.».

2.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районын «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 9 февралендә 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы«Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 20 маендагы 10 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә яңа редакциядә үзгәрешләр кертү хакында»карарын гамәлдән чыгарырга.

3.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгына теркәү органында «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Федотовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә яңа редакциядә үзгәрешләр кертү хакында» Совет карарын теркәүне тәэмин итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет ур., 6, Совет ур., 8 (мәдәният йорты бинасы), Кузьминовка авылы, Кооператив ур., 10 (СК бинасы)буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (leninogorsk.tatar.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Федотовка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе В.И.Павлова